**Казан шәһәре Совет районы**
**гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе**
**“90 нчы гимназия”**

| “Килешенде”<br>Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары<br>________________Г.Х.Шафеева. | “Раслыйм”<br>ГБМБУ “90 нчы гимназия” директоры<br>________Г.Д.Закирҗанова |
|---|---|

# “Сәләтле бала“

## әдәби түгәрәгенең 2022-2023 нче уку елына эш программасы

Төзүче: Г.Р.Габделхакова,
гомуми белем муниципаль бюджет
учреждениесе “90 нчы гимназия”нең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## Аңлатма язуы

### I Кереш өлеш.

Галимнәр сәләтсез балалар юк, һәркемнең нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышы була диләр, ә безнең бурыч – баланың сәләтен ачыклау, ихтыяҗын төрле яктан канәгатьләндерү, сәләтен үстерү. Бу уңайдан "Сәләтле бала" әдәби түгәрәге - укучылар эшчәнлеген активлаштыру, иҗади фикерләү өчен бик тә уңайлы җирлек. «Күп белдерүгә караганда, әз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләү юлларын табарга өйрәтү-мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң зурысы», - дигән әдәбият галиме Г.Ибраһимов. Минемчә, бүгенге көндә заманча технологияләрнең асылын Г.Ибраһимовның шушы фикере тулысынча раслый. Чөнки заманча технологияләр кулланып эшләү - укучыда өйрәнә торган фәнгә кызыксыну уяту, аның танып белү активлыгын үстерү һәм укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштереп, белемнәрен тирәнәйтү, сәләтләрен ачу ул.

Баланың һәвәслелеген, талантын төрлечә билгеләп була. Тиешле шартларда яшәгән балаларның 2-9 проценты бик сәләтле була. Интеллектлылыгы яшьләренә туры килгән балалар 50 процент тәшкил итә. Алар дөньяны танып белүдә һәм һөнәри осталыкта гаять зур уңышларга ирешергә, мәктәптә белем алу елларында бик сәләтле балаларга тигезләнергә мөмкин.

Сәләтле баланың укуга омтылышы, белем алу белән кызыксынуы сүрелүен алга таба төзәтү бик читен. Балачак һәм үсмерчакның һәр чоры теге яки бу белемне җиңелрәк үзләштерүгә көйләнгән. Билгеле бер яшьтә баланың танып-белү сәләте тиешенчә файдаланылмаса, алга таба аның бу сыйфаты бөтенләй югалырга мөмкин.Талантлы бала һәрвакыт үзенең җәмгыятькә кирәклеген тоеп, алга таба зур эшләр башкара алуына ышанып яшәргә тиеш.

**"Сәләтле бала" әдәби түгәрәгендә түбәндәге юнәлешләр буенча эш алып барыла:**

-укучыларда милли үзаң тәрбияләү;
-гуманитар стильдәге фикерләү сәләтен формалаштыру;
-шәхеснең үз-үзенә ышанганлык, үз-үзен күрсәтү, үз-үзен раслау, үз планнарын тормышка ашыру юнәлешендә рухи мөмкинчелекләрен үстерү;
-"сәләтле балаларның" фәнни-гамәли күнекмәләрен, иҗади мөмкинчелекләрен үстерү;

**Максат:** укучыларның сәләтләрен һәръяклап ачу һәм үстерү өчен реаль шартлар булдыру

**Бурычлар:**

1. Укучының иҗади фикерләү сәләтен үстерү.
2. Белем һәм тәрбия бирүгә комплекслы якын килеп, укучыда әхлаклылык тәрбияләү.
3. Укучының сүзлек хәзинәсен баету.
4. Укучының тумыштан булган сәләтенә үсәргә ярдәм итү, мөмкинлекләр тудыру.
5. Фәнни эшләр белән шөгыльләнү өчен җирлек булдыру.
6. Фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнашу.
7. Төрле дәрәҗәдәге бәйгеләрдә,олимпиадаларда катнашу.
8. Югары әхлакый сыйфатларга, интерактив, коммуникатив мөмкинлекләргә ия булган иҗади шәхес тәрбияләү.

Максатка ирешү һәм бурычларны үтәү өчен эш методлары һәм формалары:

- Әңгәмә;
- экскурсия;
- ИКТ куллану( компьютер, интерактив такта, электрон текстлар)

*Эш формалары:*

- Дәрес-конференция;

- мультимедиа презентацияләре;
- тестлар үтәү;
- эшлекле уен;
- диспут;
- әдәби очрашу

**Көтелгән нәтиҗәләр**

1. Туган телне тирәнтен өйрәнү;
2. Алган белем, осталык һәм күнекмәләрне гамәлдә кулланырга өйрәнү;
3. Татар телендә ирекле аралашырга өйрәнү, татар дөньясы турында күпкырлы мәгълүматлы булу;
4 . Фәнни чыганаклар, тестлар белән эшләргә өйрәнү;
5 Татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләрен төгәл күз алдына китерү, тел үсеп торсын өчен, аның көндәлек кулланышын тәэмин итү юлларын белү;
6 Төрле стильләрне аера белү, алардан файдалана белү;
7 Әдәби әсәрнең жанрын тану, әсәрнең төп идеясен аңлау;
8.Сүзлекләрнең төрләрен, төзелешен белеп, алардан иркен файдалана алу;
9. Фәнни тикшеренү эшләре язарга өйрәнү, конференцияләрдә катнашу;
10. Дөрес, сәнгатьле сөйләргә өйрәнү;
11. Төрле конкурсларда катнашу, буш вакытны файдалы итеп үткәрүгә ирешү.

**Программаның эчтәлеге.**

1. **Кереш дәрес. Программа белән таныштыру**.

Балаларны кызыксындыру, татар халкының бай хәзинәләре аша татар теленең бөеклегенә инандыру, телне өйрәнү мохитен тудыру.

2. **Татар халык авыз иҗаты.**

Татар халык авыз иҗатының жанрларын, билгеләмәләрен, аларга хас сыйфатларны белү.

Тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар, хәрәкәтле такмаклар, мәкальләр, әйтемнәр җыю. (Хәрәкәтле такмакларның максаты – авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, хәрәкәтләрне такмаклау гамәле белән координацияләү, хәрәкәтләр сайлаганда балаларга иҗат өчен мөмкинлекләр бирү, оялу, киеренкелек хисеннән котылу өчен шартлар тудыру). [ 6. Ягъфәров Р.И., Татар халык уеннары // Казан: Татар. кит. нәшр., - 1998. – 156 бит.]

Татар халык әкиятләре белән танышу. Әкиятләрнең төрләре. Татар һәм рус халык әкиятләре арасында охшаш һәм аермалы яклар.

Мәзәкләр. Татарча мәзәкләр уку. [3. Кукшин Р., Татар балалар антологиясе // Казан: Татар. кит. нәшр., -1983. - 3 бит.]

Татар халык җырлары белән танышу. Татар халык җырларын башкаручы артистлар.

Бәетләр, аларның төрләре, барлыкка килүе. Хәзерге чор бәетләре белән танышу.

3. **Татар халык бәйрәмнәре.**

Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү. “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Карга бәйрәме “Сабантуй” бәйрәмнәре. “Сөмбелә” бәйгесендә катнашу өчен әзерлек эшләре алып бару. [1. Әхмәтов С., Уйныйбыз да, җырлыйбыз да... // Яр Чаллы: КамАЗ акционерлык җәмгыятенең газета – кит. нәшр., - 1991. -9 бит. ]

Татар халкының дини бәйрәмнәре һәм йолалары.

Викторина “ Тел дигән дәрья бар...”.

4. **Татар кызы.Татар егете.**

Татар кызы, татар егетенә хас сыйфатлар турында сөйләшү. Татар халкының милли киемнәре белән таныштыру. Кием әдәпләре турында әңгәмә оештыру. [4. Нүрзия, Татар сынлы сәнгате // Казан: Татар. кит. нәшр., - 1999. – 16бит.]

“Татар кызы” ,”Татар егете” бәйгеләренә әзерлек.

5. **Туган тел фәненнән республика олимпиадасының мәктәп һәм шәһәр турларына әзерлек.**
   Грамматиканың бүлекләрен (фонетика, лексикология, сүз ясалышы, морфология, синтаксис) кабатлау. Анализ ясау күнекмәләрен булдыру. Татар теле галимнәре турында мәгълүмат бирү.
6. **Әдәбият фәненнән республика олимпиадасының мәктәп һәм шәһәр турларына әзерлек.**
   Әдәбият тарихы. Әдәбиятның чорларга бүленеше.
   Борынгы әдәбияттан бүгенге чорга кадәр иҗат иткән язучылар иҗатын искә төшерү.
   Хәзерге чор прозаиклары иҗаты белән танышу.
   Бугенге заман шигъриятенә күзәтү. Р.Миңнуллин, Ф.Яруллин, Р.Әхмәтҗанов, Ш.Галиев, Г.Мөхәммәтшин, Р.Вәлиев, Зөлфәт, Л.Шәех шигырьләренең теле.
7. **Театр яктылыкка , нурга илтә...**
   Хәзерге чор драматурглары иҗаты белән танышу.
   Казан шәһәрендәге театрлар турында мәглүмат бирү.
   Г.Кариев, К.Тинчурин, Г.Камал теарларына экскурсия. Артистлар белән очрашу.

**8. Казан каласы – баш кала...**

Шәһәребез тарихы, аның истәлекле урыннары, күренекле шәхесләре турында белемнәрне киңәйтү.

**9.Үз биеклеге булуда кешенең бөеклеге.**

“Әдәби җомга” утырышында шагыйрьләр белән очрашуга әзерлек һәм очрашу кичәләре.

Мәктәп, район, шәһәр, республика күләмендәге бәйгеләргә әзерлек.

**10.Татар матбугаты**.

Татар телендә нәшер ителүче газеталар, журналлар белән таныштыру.

**11.Иҗат- гүзәл гамь ул**.

Төрле темаларга шигырьләр, хикәяләр иҗат итү, аларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау

**12. Риторика-чыгыш ясарга һәм аралашырга өйрәтүче фән.**

Риторика. Сәнгатьле сөйли белү осталыгы. Үзебез иҗат иткән шигырьләрне, язучылар иҗатын сәнгатьле уку. Сәхнә әдәбе, сәхнә культурас

**13. Фәнгә бер адым.**

Фәнни эш язу тәртибе. Фәнни конференцияләрдә чыгыш ясау осталыгы.

**14.Татар телевидениесе**.

Татар телевидениесе турында әңгәмә оештыру. Татарча тапшырулар турында мәгълүмат бирү. ”ТНВ”, “Шаян” ТВ тапшырулары. Татарча мультфильмнар карау.

**15.Тел дигән дәрья бар...**

Электрон китапханә.

Татарча википедия.

Еллык эшләргә нәтиҗә ясау

**Календарь-тематик план**

| № | Тема | Сәгать |
|---|---|---|
| 1 | **Кереш дәрес. Программа белән таныштыру.** (Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү, эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау) | 2 |
| | **Татар халык авыз иҗаты** | |
| 2 | Татар халык авыз иҗаты. Жанрлары. | 2 |
| 3-4 | Тизәйткечләр, санамышлар.<br>Табышмаклар, хәрәкәтле такмаклар, мәкальләр, әйтемнәр җыю. | 4 |
| 5-6 | Татар халык әкиятләре. Әкиятләрнең төрләре.<br>“ Әкият – минем балачак дустым” темасына сөйләшү. | 4 |
| 7 | Татар һәм рус халык әкиятләре арасында охшаш һәм аермалы яклар. | 4 |
| 8 | Мәзәкләр. Аларга хас сыйфатлар. Татарча мәзәкләр уку. | 2 |
| 9-10 | Татар халык җырлары белән танышу. Татар халык җырларын башкаручы артистлар. | 6 |
| 11 | Бәетләр, аларның төрләре, барлыкка килүе. Хәзерге чор бәетләре белән танышу. | 4 |
| | **Татар халык бәйрәмнәре.** | |
| 12 | Һәр халыкның үз бәйрәме. | 2 |
| 13 | Татар халык бәйрәмнәре. “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы” “Сабантуй” бәйрәмнәре. | 4 |
| 14 | Татар халкының дини бәйрәмнәре һәм йолалары. | 2 |
| 15-16 | ”Сөмбелә” бәйгесенә әзерлек. | 2 |
| | **Татар кызы. Татар егете.** | |
| 17 | Татар кызы, татар егетенә хас сыйфатлар. | 2 |
| 18 | Татар халкының милли киемнәре. Кием әдәпләре | 2 |
| 19-20 | “Татар кызы” ,”Татар егете”. “Татар сүзе”, “Җәлил укулары” бәйгеләренә , “Айтматов укулары”на әзерлек | 6 |
| | **Туган тел фәненнән республика олимпиадасының мәктәп һәм шәһәр турларына әзерлек.** | |
| 21 | Туган тел фәненнән республика олимпиадасының мәктәп һәм шәһәр турына әзерлек. | 4 |
| 22-23-24 | Грамматиканың бүлекләрен (фонетика, лексикология, сүз ясалышы, морфология, синтаксис) кабатлау | 6 |
| 25 | Грамматик анализ ясау күнекмәләрен булдыру | 2 |
| 26 | Татар теле галимнәре турында мәгълүмат. | 2 |
| | **Әдәбият фәненнән республика олимпиадасының мәктәп һәм шәһәр турларына әзерлек.** | |
| 27 | Әдәбият тарихы. Әдәбиятның чорларга бүленеше | 2 |
| 28-29 | Борынгы әдәбияттан бүгенге чорга кадәр иҗат иткән язучылар | 6 |

| | | |
|---|---|---|
| | иҗатын искә төшерү. | |
| 30 | Хәзерге чор прозаиклары иҗаты белән танышу. | 6 |
| 31-32 | Бугенге заман шигъриятенә күзәтү. Р.Миңнуллин, Ф.Яруллин, Р.Әхмәтҗанов, Ш.Галиев, Г.Мөхәммәтшин, Р.Вәлиев, Зөлфәт, Л.Шәех шигырьләренең теле. | 4 |
| | **7.Театр яктылыкка , нурга илтә...** | |
| 33-34 | Г.Кариев театрына экскурсия.Казан шәһәрендәге театрлар. | 4 |
| 35-36 | Хәзерге чор драматурглары иҗаты. | 4 |
| 37-38-39 | К.Тинчурин, Г.Камал театрларына экскурсия. Артистлар белән очрашу. | 6 |
| | **8. Казан каласы – баш кала...** | |
| 40 | Казан шәһәре тарихы, аның истәлекле урыннары. | 2 |
| 41-42 | Казанда яшәгән күренекле шәхесләр. | 4 |
| | **9. Үз биеклеге булуда кешенең бөеклеге.** | |
| 43-44-45 | “Әдәби җомга” утырышын үткәрүгә әзерлек һәм очрашу кичәләре. | 6 |
| 46-47-48-49 | Мәктәп, район, шәһәр, республика күләмендәге бәйгеләргә әзерлек | 8 |
| | **10. Фәнгә бер адым.** | |
| 50-51 | “Фәнгә бер адым”. Фәнни эш язу тәртибе | 4 |
| 52-53-54 | Фәнни эш язу тәртибе. Фәнни конференцияләрдә чыгыш ясау осталыгы. | 6 |
| | **11. Татар матбугаты.** | |
| 55-56 | Татар матбугаты. Татар телендә нәшер ителүче газеталарга, журналларга күзәтү. | 4 |
| 57-58 | Газета, журнал битләрендә үз мәкаләләреңне күрү өчен нишләргә кирәк? | 4 |
| | **12. Иҗат- гүзәл гамь ул.** | |
| 59-60-61-62 | Төрле темаларга шигырьләр, хикәяләр иҗат итү, аларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау. | 8 |
| | **13. Риторика-чыгыш ясарга һәм аралашырга өйрәтүче фән.** | |

| | | |
|---|---|---|
| 63 | Риторика. Сәнгатьле сөйли белү осталыгы. | 2 |
| 64-65 | Үзебез иҗат иткән шигырьләрне, язучылар иҗатын сәнгатьле уку. | 4 |
| 66-67-68 | Сәхнә әдәбе, сәхнә культурасы. Шәһәр, республика күләмендәге бәйгеләргә әзерлек. | 6 |
| | **14. Татар телевидениесе**. | |
| 69-70 | Татар телевидениесе. Татарча тапшырулар. ”ТНВ”, “Шаян” ТВ тапшырулары. Татарча мультфильмнар карау. | 6 |
| | **15.Тел дигән дәрья бар...** | |
| 71 | Викторина “ Тел дигән дәрья бар...” | 2 |
| 72 | Электрон китапханә | 2 |
| 73 | Татарча викепидия | 2 |
| 74 | Еллык эшләргә нәтиҗә ясау | 2 |
| | | **166 сәг**. |

**Укытучылар өчен кулланылган әдәбият**


1. Гарифуллин В.Г. "Үткен каләм, үткер күз”. Казан: Тат. китап нәшр.,1995 – 165 б.
2. Гарифуллин В.Г. "Журналистның иҗади эшчәнлеге нигезләре” Казан, 2004 – 205 б.
3. Курбатов Х.Р. "Сүз сәнгате. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы”. Казан: "Мәгариф” нәшр., 2002. – 200 б.
4. Хәйруллина А.Х. Тел күрке – сүз (матур сөйләргә өйрән). / А.Х.Хәйруллина. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1978. – 113 б.
5. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. / И.М.Низамов. Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. – 144 б.
6. Ф.С.Сафиуллина. Г.Б.Ибраһимов. Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел. К., 1998
7. Д.Ф.Заһидуллина,Ә.М.Закирҗанов,Т.Ш.Гыйләҗев.Татар әдәбияты. Теория. Тарих. Казан, 2006
8. Әдәбият белеме сүзлеге. Казан, 1990.
9. Ф.Хатипов. Әдәбият теориясе. Казан, 2000.


**Укучылар өчен кулланылган әдәбият һәм газета - журналлар исемлеге**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. - Казан: Мәгариф, 2007.
2. Бәширова И. Сүз белән сурәт ясау. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1974.
3. Вәлиуллин И.Ә. Һәр шагыйрь - бер дәрья... - Казан: Татар, кит.нәшр.,2006. - 208 б.
4. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. -Казан: Татар.кит.нәшр.,1988. - 86 б.
5. Гарифуллин В.З. Үткен каләм, үткер күз. - Казан: Тат. кит. нәшр.,1995.
6. "Ватаным Татарстан» газетасы
7. "Казан утлары" журналы
8. "Сабантуй" журналы
9. "Мәдәни җомга" газетасы
10. "Сөембикә" журналы
11. " Татарстан яшьләре" газетасы
12. "Идел” журналы
13. "Шәһри Казан" газетасы
14. "Ялкын" журналы
15. “Гаилә һәм мәктәп” журналы